**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2024 елның «27» мартыннан №43-332

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2015 елның 18 мартындагы 42-247 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 91, 92 һәм 93 статьялары нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2015 елның 18 мартындагы 42-247 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына (№2-9, 16.10.2015 ел; №9-32,11.02.2016 ел; №18-82, 28.09.2016 ел; №20-103, 14.12.2016 ел; №25-132, 17.04.2017 ел; №28-150 17.08.2017 ел; №31-180, 14.12.2017 ел; №37-209, 25.05.2018 ел; №43-252, 13.12.2018 ел: №50-299, 05.07.2019 ел; №61-378, 04.06.2020 ел; №10-70, 02.06.2021ел; №16-124, 09.12.2021ел; №24-181, 7.07.2022 ел; №32-245, 16.03.2023 ел карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Уставның 7 статьясында:

1 өлешнең 12 пунктына «, шул исәптән әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнар нигезендә район территориясендә планлаштырыла торган хуҗалык һәм башка эшчәнлек буенча иҗтимагый фикер алышулар оештыру һәм уздыру» сүзләрен өстәргә;

1 өлешнең 31 пунктын түбәндәге редакциядә бирергә:

«31) балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча җирлекара характердагы чараларны оештыру һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программаларны эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны мониторинглауны оештыру һәм гамәлгә ашыру;»;

1 өлешнең 32 пунктына «, шулай ук рекреацион максатлар өчен су объектларыннан файдалану кагыйдәләрен» сүзләрен өстәргә;

1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 41 пункт өстәргә:

«41) әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектларын ачыклау һәм муниципаль район милкендәге җир кишәрлекләре чикләрендә урнашкан территорияләргә карата мондый зыянны бетерү.";

1.2. Уставның 6.1 статьясында:

1 өлешнең 16 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16) балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча чараларны оештыру һәм гамәлгә ашыру, җирлектә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программаларны эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны мониторинглауны оештыру һәм гамәлгә ашыру;»;

1 өлешнең 17 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17) Россия Федерациясенең су законнарында билгеләнгән чикләрдә су объектлары милекчесенең вәкаләтләрен гамәлгә ашыру, шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен гомуми файдаланудагы су объектларыннан файдалану кагыйдәләрен билгеләү, моңа гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр полосаларына иректе керүен тәэмин итү дә керә, шулай ук су объектларыннан рекреацион максатлар өчен файдалану кагыйдәләрен билгеләү;».

1.3. 33 статьядагы 28 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«28) муниципаль хокукый актларны халыкка җиткерү, муниципаль берәмлек халкына рәсми мәгълүмат җиткерү өчен массакүләм мәгълүмат чарасы һәм (яисә) челтәр басмасы учреждениесе;».

1.4. Уставның 48 статьясында:

1 өлештә 3 пунктның бишенче абзацына «, шул исәптән әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнар нигезендә район территориясендә планлаштырыла торган хуҗалык һәм башка эшчәнлек буенча иҗтимагый фикер алышулар оештыру һәм уздыру» сүзләрен өстәргә;

1 өлешнең 3 пунктның сигезенче абзацына «, шулай ук рекреацион максатлар өчен су объектларыннан файдалану кагыйдәләрен» сүзләрен өстәргә;

1 өлешнең 5 пунктын түбәндәге эчтәлекле уналтынчы абзац белән тулыландырырга:

«- әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектларын ачыклый һәм муниципаль район милкендәге җир кишәрлекләре чикләрендә урнашкан территорияләргә карата мондый зыянны бетерә.».

1 өлешнең 6 пунктындагы җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча җирлекара характердагы чараларны оештыру һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнаша, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшли һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программаларны эшли һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны мониторинглауны оештыра һәм гамәлгә ашыра;»;

1 өлешнең 8 пунктындагы алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- Россия Федерациясенең су законнарында билгеләнгән чикләрдә су объектлары милекчесенең вәкаләтләрен гамәлгә ашыру, шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен гомуми файдаланудагы су объектларыннан файдалану кагыйдәләрен билгеләү, моңа гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр полосаларына

ирекле керүен тәэмин итү дә керә, шулай ук су объектларыннан рекреацион максатлар өчен файдалану кагыйдәләрен билгеләү;».

1.5. Уставның 49 статьясындагы 4 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Аерым оештыру-күрсәтмә функцияләрен гамәлгә ашыру өчен район Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарларга ия. Район Башкарма комитеты җитәкчесе җитди сәбәпләр аркасында вакытлыча булмаганда яки үз бурычларын үтәү мөмкинлеге булмаганда, вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта, аның вәкаләтләрен район Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары (икътисад буенча) башкара»;

1.6. Уставның 57 статьясындагы 1 өлешендә «районның Финанс-бюджет палатасы җирле үзидарәнең даими эшләүче финанс органы булып тора,» сүзләрен «районның Финанс-бюджет Палатасы даими эшләүче җирле үзидарә органы булып тора,» сүзләренә алмаштырырга.

1.7. Уставның 68.1 статьясында: .

1 өлешнең 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) кешенең федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, аның ягы булган мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм (яки) җайга салу буенча чаралар күрмәве;».

1 өлешнең 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) зат тарафыннан үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, тулы булмаган белешмәләр йә, әгәр федераль законнарда башкасы билгеләнмәгән булса, белә торып дөрес булмаган белешмәләр тапшыру ;»;

2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Үзенә буйсынган затның мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында билгеле булган муниципаль вазыйфаны биләүче зат ышанычын югалту белән бәйле рәвештә эштән чыгарылырга (вазыйфасыннан азат ителергә) тиеш, шулай ук муниципаль вазыйфаны биләүче зат, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, яклар аңа буйсынган зат булган мәнфәгатьләр конфликтын катлауландыру һәм (яисә) җайга салу чаралары күрелмәгән очракта.».

1.8. Уставның 76 статьясын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«76 статья. Муниципаль хокукый актларны халыкка җиткерү һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе.

1. Кеше һәм граждан хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы муниципаль норматив хокукый актлар, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге гамәлгә куйган оешмаларның хокукый статусын билгели торган муниципаль норматив хокукый актлар, шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр рәсми игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

2. Муниципаль норматив хокукый актны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүне рәсми рәвештә халыкка җиткерү түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында тулы текстны рәсми бастырып чыгару (https://pravo.tatarstan.ru; массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан 2013 елның 17 декабрендә бирелгән ЭЛ № ФС77-60244 номерлы таныклык) яки вакытлы матбугат басмасында - «Яңа Чишмә хәбәрләре» («Шешминская новь») https://novoshishminsk.ru; газета Идел буе Идарәсендә массакүләм коммуникацияләр һәм мәдәни мирасны саклау өлкәсендәге законнарның үтәлешен күзәтү буенча федераль хезмәтнең Идел буе

идарәсендә 2007 елның 30 ноябрендә теркәлгән, теркәлү турында таныклыкның номеры ПИ №ФС7-4787);

2) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында https://novosheshminsk.tatarstan.ru урнаштыру.

3. Гражданнарның Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталыннан файдалана алуын тәэмин итү өчен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә тоташу пунктлары Яңа Чишмә ав., Совет ур., 80 йорт (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы һәм Башкарма комитеты биналары); Яңа Чишмә ав., Заливная ур., 4 йорт («Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының үзәкләштерелгән китапханә системасы» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе бинасы); Яңа Чишмә ав., Ленин ур., 37А йорт («Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күп функцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенең Яңа Чишмә филиалы бинасы) адреслары буенча эшли.

4. Җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган муниципаль норматив хокукый актлар, килешүләр, федераль закон белән таратуы чикләнгән белешмәләр булган муниципаль хокукый актлардан яисә аларның аерым нигезләмәләреннән тыш, аларны имзалаган көннән алып 10 эш көне эчендә халыкка игълан ителә.

5. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең салымнар һәм җыемнар турындагы норматив хокукый актлары Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә үз көченә керә.

6. Әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелмәгән муниципаль хокукый актлар, әгәр актның үзе тарафыннан башкасы билгеләнмәгән булса, имза салынган көннән үз көченә керә.

6. «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә тиешле сайтларның домен исемнәре һәм аларны массакүләм мәгълүмат чаралары буларак теркәү турында мәгълүматлар күрсәтелгән вакытлы басмалар, челтәр басмалары исемлеге, аларда муниципаль хокукый актлар игълан ителә (рәсми басылудан тыш), шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүләр Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгының хокукый актын бастырып чыгару юлы белән бөтен кешегә җиткерелә»

2. Әлеге карарны законда билгеләнгән тәртиптә дәүләт тарафыннан теркәү уздыру өчен юлларга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында дәүләт теркәве узганнан соң «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә: http//pravo.tatarstan.ru, «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http// novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән хезмәттәшлек буенча даими комиссиясенә йөкләнә.

Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы В. М. Козлов